ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИКИФОРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Карла Маркса, д.2, с. Никифорово,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422166

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ НИКИФОРОВО АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Карл Маркс ур., 2 нче йорт, Никифорово авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422166

тел.(факс): (85563) 2-42-38; e-mail: Nikifor.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление                                                  Карар

от «28» июль 2025 ел.                                        № 8

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Никифорово авыл җирлеге Башкарма
комитетының
02.03.2023 елның 17 санлы карарына
үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 28.12.2020 ел, № 2314 санлы «Гражданнар гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булмаган яктырткыч җайланмалар, электр лампалары өлешендә җитештерү һәм куллану калдыкларын тиешенчә җыю, туплау, файдалану, зарарсызландыру, транспортировкалау һәм урнаштыру кагыйдәләрен раслау турындагы” (2024 нче елның 14 мартында серткән үзгәрешләр белән) карарына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы "Никифорово авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампаларны туплау урынын (урынын) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында мәгълүмат бирү турында» 02.03.2023 ел, №17 карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Карарның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Никифорово авыл җирлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмешле лампалар туплану урыннарының урнашуы турында әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында мондый урыннарның урнашуы турында мәгълүмат урнаштыру юлы белән, шулай ук мәгълүматны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Никифорово авыл

җирлеге җирле үзидарә органнары биналарындагы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән кулланучыларга хәбәр итәргә ».

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), шулай ук Мамадыш муниципаль районының "Интернет"мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Никифорово авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Җитәкче: С.Н.Степанов